Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

# КАРАР №LIV-5

2020 елның 5 августы

Балык Бистәсе штп.

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвеннән азат итү шартлары турында**

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы Күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы Күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән авиапассажирлар ташу, аэропорт эшчәнлеге, автопассажирлар ташу, мәдәният, ял һәм күңел ачу оештыру, физкультура-сәламәтләндерү эшчәнлеге һәм спорт, туристлык хезмәтләре, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, өстәмә белем бирү, дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре, конференцияләр һәм күргәзмәләр оештыру, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеге (ремонт, юу, химчистка, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары хезмәтләре) өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгатеннән соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләүләреннән мондый арендаторларны азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзүне. Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү, әгәр аренда килешүендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен), әлеге төр

эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында һәм күрсәтелгән төр эшчәнлекне (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне файдалануны раслаучы документлар булып арендага бирү каралган очракта гамәлгә ашырыла;

б) әлеге карар үз көченә кергән көннән алып өч эш көне эчендә арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның "а" пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итүнең Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге әлеге күрсәтмәнең 1 пунктындагы "а" пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча түләнмәгән бурычы булмаган арендаторларга карата гамәлгә ашырылганын билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Ф.М.Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы — И.Р. Таҗетдинов